СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**31.10.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 432**

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 103 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 147 номерлы, 2023 елның 28 декабрендәге 355 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы карары , «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 103 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 147 номерлы, 2023 елның 28 декабрендәге 355 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «планлаштыру структурасы элементы» - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе.

2. Әлеге карар, аны рәсми бастырып чыгарган вакыттан, үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы

Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**